**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об использовании лесов в Республике Татарстан»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
23 ноября 2023 года

## Статья 1

Внести в Закон Республики Татарстан от 22 мая 2008 года № 22-ЗРТ «Об использовании лесов в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2008, № 5 (I часть); 2009, № 12 (I часть); 2011, № 6 (I часть); 2012, № 1, № 12 (I часть); 2013, № 12 (I часть); 2014, № 5, № 12 (II часть); 2015, № 11 (I часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 40 (часть I); 2017, № 27 (часть I); 2018, № 44 (часть I); 2019, № 2 (часть I); 2020, № 1 (часть I); 2021, № 57 (часть I), № 93 (часть I); 2022, № 3 (часть I); 2023, № 27 (часть I), № 35 (часть I) следующие изменения:

1) в статье 1:

а) в пункте 2 слова «функции по контролю и надзору в области лесных отношений» заменить словами «федеральный государственный лесной контроль (надзор)»;

б) в пункте 6 слова «функции по контролю и надзору в области лесных отношений» заменить словами «федеральный государственный лесной контроль (надзор)»;

в) дополнить пунктами $6^2$ и $6^3$ следующего содержания:

«$6^2$) утверждение плана противопожарного обустройства лесов на территории Республики Татарстан по согласованию с федеральным органом исполнительной власти, осуществляющим федеральный государственный лесной контроль (надзор);

$6^3$) согласование решения федерального органа исполнительной власти, осуществляющего федеральный государственный лесной контроль (надзор), о применении мер экстренного реагирования;»;

2) в части 3 статьи 3:

а) дополнить пунктами $1^1$ и $1^2$ следующего содержания:

«$1^1$) разработка плана противопожарного обустройства лесов на территории Республики Татарстан;

$1^2$) разработка и утверждение плана противопожарного обустройства лесов на территории лесничества;»;

б) в пункте $13^9$ слова «осуществление мер пожарной безопасности и тушение лесных пожаров» заменить словами «установление зон контроля лесных пожаров, выполнение мер пожарной безопасности в лесах, тушение лесных пожаров», после слов «в целях тушения лесных пожаров» дополнить словами «, а также осуществления мер экстренного реагирования»;

3) статью 5 изложить в следующей редакции:

«Статья 5. **Порядок заключения договора купли-продажи лесных насаждений, расположенных на землях лесного фонда, гражданами для собственных нужд без проведения торгов**

1. Граждане осуществляют заготовку древесины для собственных нужд на основании договора купли-продажи лесных насаждений, расположенных на землях лесного фонда, гражданами для собственных нужд без проведения торгов (далее – договор купли-продажи лесных насаждений для собственных нужд).

2. Гражданин, заинтересованный в заключении договора купли-продажи лесных насаждений для собственных нужд (далее – заявитель), обращается в уполномоченный орган с заявлением о заключении договора купли-продажи лесных насаждений для собственных нужд (далее – заявление), в котором указываются:

1) фамилия, имя, отчество (последнее – при наличии) заявителя, данные о регистрации по месту жительства (месту пребывания), данные документа, удостоверяющего личность;

2) наименование лесничества, в границах которого предполагается осуществить куплю-продажу лесных насаждений;

3) требуемый объем древесины, ее качественные показатели и цель заготовки.

3. Заявление может быть подано в письменной форме через многофункциональный центр предоставления государственных и муниципальных услуг или в форме электронного документа, подписанного электронной подписью, посредством федеральной государственной информационной системы «Единый портал государственных и муниципальных услуг (функций)», государственной информационной системы Республики Татарстан «Портал государственных и муниципальных услуг Республики Татарстан».

4. В течение 10 рабочих дней со дня поступления заявления уполномоченный орган заключает с заявителем договор купли-продажи лесных насаждений для собственных нужд или принимает решение об отказе в заключении такого договора, уведомив об этом заявителя указанным в заявлении способом. В случае принятия решения об отказе в заключении договора купли-продажи лесных

насаждений для собственных нужд в уведомлении должна быть указана причина такого отказа.

5. Уполномоченный орган принимает решение об отказе в заключении договора купли-продажи лесных насаждений для собственных нужд в следующих случаях:

1) представлены документы, содержащие неполную и (или) недостоверную информацию;

2) указанный в заявлении объем древесины превышает нормативы, установленные частью 1 статьи 7 настоящего Закона;

3) в указанном заявителем лесничестве отсутствуют лесные насаждения, достаточные для заготовки указанных в заявлении объемов древесины с требуемыми качественными показателями;

4) не соблюдены сроки, установленные частью 1 статьи 7 настоящего Закона.

6. Информация о лесничествах, в границах которых расположены лесные насаждения, пригодные для заготовки древесины гражданами для собственных нужд, размещается на официальном сайте уполномоченного органа в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».».

**Статья 2**

1. Настоящий Закон вступает в силу по истечении 10 дней после дня его официального опубликования, за исключением пунктов 1 и 2 статьи 1 настоящего Закона.

2. Пункты 1 и 2 статьи 1 настоящего Закона вступают в силу с 1 января 2024 года.

Глава (Раис)
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казань, Кремль
04 декабря 2023 года
№ 120-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 23 ноябрендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 1, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:

а) 2 пунктта «урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен» сүзләрен «федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген)» сүзләренә алмаштырырга;

б) 6 пунктта «урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен» сүзләрен «федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген)» сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле $6^2$ һәм $6^3$ пунктлар өстәргә:

«$6^2$) Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны янгынга каршы төзекләндерү планын федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы белән килештереп раслау;

$6^3$) ашыгыч чаралар күрүне куллану турында федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы карарын килештерү;»;

2) 3 статьяның 3 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ һәм $1^2$ пунктлар өстәргә:

«1[1]) Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны янгынга каршы төзекләндерү планын эшләү;

1[2]) урманчылык территориясендә урманнарны янгынга каршы төзекләндерү планын эшләү һәм раслау;»;

б) 13[9] пунктта «янгын куркынычсызлыгы чараларын гамәлгә ашыру һәм урман янгыннарын сүндерү» сүзләрен «урман янгыннарын контрольдә тоту зоналарын билгеләү, урманнарда янгын куркынычсызлыгы чараларын башкару, урман янгыннарын сүндерү» сүзләренә алмаштырырга, «урман янгыннарын сүндерү максатларында» сүзләрен «урман янгыннарын сүндерү, шулай ук ашыгыч чаралар күрүне гамәлгә ашыру максатларында» сүзләренә алмаштырырга;

3) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 статья. **Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен торглар үткәрмичә урман фонды җирләрендә урнашкан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзү тәртибе**

1. Гражданнар үз ихтыяҗлары өчен агач әзерләүне гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен торглар үткәрмичә урман фонды җирләрендә урнашкан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе (алга таба – үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе) нигезендә башкаралар.

2. Үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзергә теләгән граждан (алга таба – гариза бирүче) вәкаләтле органга үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзү турында гариза (алга таба – гариза) белән мөрәҗәгать итә, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны (тору урыны) буенча теркәлү турында белешмәләр, шәхесен таныклый торган документ белешмәләре;

2) чикләрендә урман утыртмаларын сату-алу күздә тотыла торган урманчылык исеме;

3) агачның таләп ителә торган күләме, аның сыйфат күрсәткечләре һәм аны әзерләү максаты.

3. Гариза язма рәвештә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша яисә, «Дәүләт хезмәтләре (функцияләре) һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтүнең бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын, «Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасын кулланып, электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә бирелергә мөмкин.

4. Гариза алган көннән алып 10 көн эчендә вәкаләтле орган гариза бирүче белән үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзи яисә мондый шартнамә төзүдән баш тарту турында, гариза бирүчегә бу хакта гаризада күрсәтелгән ысул белән хәбәр итеп, карар кабул итә. Үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, хәбәрнамәдә мондый баш тартуның сәбәбе күрсәтелергә тиеш.

5. Вәкаләтле орган үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында карарны түбәндәге очракларда кабул итә:

1) тулы булмаган һәм (яисә) дөрес булмаган мәгълүмат булган документлар тәкъдим ителсә;

2) агачның гаризада күрсәтелгән күләме әлеге Законның 7 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән нормативлардан артып китсә;

3) гариза бирүче күрсәткән урманчылыкта гаризада күрсәтелгән таләп ителә торган сыйфат күрсәткечләренә ия агач күләмнәрен әзерләү өчен җитәрлек урман утыртмалары булмаса;

4) әлеге Законның 7 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән сроклар үтәлмәсә.

6. Чикләрендә гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен агач әзерләүгә яраклы урман утыртмалары урнашкан урманчылыклар турында мәгълүмат вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 һәм 2 пунктлары 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 04 декабрь
№ 120-ТРЗ